| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31.05.2021 с. Сарманово № 37

« Сарман муниципаль районы муниципаль берәмлек башлыклары, муниципаль берәмлек башлыклары урынбасарлары, Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе хезмәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында» 2018 елның 14 маендагы 122 номерлы Сарман муниципаль районы Советы карары белән расланган пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, Сарман муниципаль районы муниципаль вазыйфасын биләүче затка бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 15 гыйнварындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә Сарман муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.«Сарман муниципаль районы муниципаль берәмлеге башлыклары, муниципаль берәмлек башлыклары урынбасарлары, Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе хезмәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында» 2018 елның 14 маендагы 122 номерлы Сарман муниципаль районы Советының карары белән расланган пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка, пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә эштән чыгарылганда, эштән азат ителгән затка, муниципаль вазыйфа статусын биләүче затның муниципаль вазыйфа стажы кимендә биш ел яисә җирле үзидарә органы вәкаләтләренең бер тулы срогы булганда, сайланулы вазыйфа

буенча айлык акчалата түләп, кимендә биш ел яисә җирле үзидарә органы вәкаләтләренең бер тулы срогы булганда һәм хезмәтнең шуннан соңгы тулы елында өстәмә рәвештә бер айлык акчалата буенча, әмма муниципаль вазыйфа биләүче затның акчалата түләү күләме кимендә ун тапкыр түләнә. Хезмәт стажы муниципаль вазыйфаны биләүче затны эштән азат итү көненә билгеләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Совет Рәисе — Ф. М. Хөснуллин